**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ядегәр авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**3 ноябрь 2021 ел** **№2**

**«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 15 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
2. 2021 елның 15 ноябрендә 18 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
3. 2021 елның 19 ноябрендә 19 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ядегәр авылында кышын-җәен юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Ядегәр авылының С.Сәйдәш, Дуслык,Гагарин, Көнчыгыш, Ленин, Такташ урамнары буенча юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;

- Ядегәр авылының чишмәсен һәм территориясен төзекләндерү, ремонтлау (материаллар алу) проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;

- Ядегәр авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;

- торак пунктка керү һәм чыгу юлында видеокамералар урнаштыру һәм килешү буенча түләү;

- су белән тәэмин итү челтәрләре өчен проект-смета документларын эшләү, су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау, су насосын алу һәм килешү буенча түләү;

- “Сабантуй” үткәрү урынының территориясен төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм килешү буенча түләү;

- Ядегәр авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү һәм килешү буенча түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Җыенны оештыручы итеп Ядегәр авылы башкарма комитетын билгеләргә.

7.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ЯДЫГЕРЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ОГРН 1021607752836 Совет Ядыгерьского сельского поселения ИНН 1623001639